БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 март 2019 ел № 169

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенец муниципаль мөлкәтен (төп средстволарын) исәптән төшерү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1.«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен (төп средстволарын) исәптән төшерү тәртибе турындагы Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2013 елның 19 декабрендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәтне исәптән чыгару тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 194 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен (төп средстволарын) исәптән төшерү тәртибе турындагы Нигезләмәнен үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин